

Россия һәм Мордовиябез очен 2018 ел истәлекле иде. Футбол буенча vткән Ботендонья Чемпионаты хәтерләргә тирән уелып калды.
Мин vзем бу тор спортны бик тә яратам, шуна олы вакыйганын һәрбер мизгелен хәтеремдә калдырырга телим. Ноябрь аенда Дубенка районы Кочкурово гомуми белем бирvче урта мәктәбебезгә “Спорт яратучы Мордовия” дигән теманы ачыклаган “Сvз сәнгате” («Искусство слова») инша конкурсынын юлламасы килде һәм укучым Ильнур Рахметуллов нәкъ бу теманы ачыклап инша язачагына бер дә шикләнмичә тотынды. Ул «Публицистика» номинациясенен «Хат» жанрын сайлады. Ильнур минем житәкчелегемдә яраткан футболисты Криштиану Роналдуга хат язды. Ильнур хатында Роналдунын футбол уйнауда булган стилен, анын матур штрафнойларын, оста пенальтиларын ошатуын белдерде. Шулай ук хатта республикабыз очен, спорт олкәсендә булган унышларыбыз очен горур булуы турында да язды. Ботендонья Чемпионатында сборныебызнын шундый нәтижәле уены очен бик шат һәм горур икәнен белдерде.
Шулай ук Ильнур Рахметуллов футбол, баскетбол, лапта һәм башка тор уеннарын уйнарга ойрәткән vзенен физкультура укытучысы Михаил Анатольевич Стволков турында да хатында сойләде.
Нәтижәдә, Дубенка районында укучым Ильнур Рахметуллов «Публицистика» номинациясендәге иншасы белән 10-13 яшьлекләр арасында лаеклы беренче урынны яулады һәм Саранск-тагы нәтижә ясала торган конкурснын республика турына жибәрелде. Январь ае азагында нәтижәләр билгеле булды. Зур унышка без бик шат, чонки Ильнур Рахметуллов ярышта беренче урын алып, Дубенка районы Кочкурово мәктәбенә жинv алып килде.

**Альфия Узбякова**, *Кочкурово мәктәбе укытучысы*